# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сойки авыл җирлегенең Сойки авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2022 елның 10 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сойки авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сойки авыл җирлегенең Сойки авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән җир һәм вак таш сатып алу, йөкләү, ташу, салу, җәйге һәм кышкы юлларны тоту);

- ТКО туплау мәйданчыкларын төзү, ТКО җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (шул исәптән ТКО мәйданчыкларын саклау өчен төзелеш материаллары сатып алу);

- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (шул исәптән зиратны саклау өчен төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы Сойки авылы Красноармейская урамы, Авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сойки авылы Колхоз йорты 16а, китапханә бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сойки авыл җирлеге Башлыгы: П.В.Сорокин